ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында «дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычлары, хокуклары һәм вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен дәүләт органының административ регламенты, дәүләт органындагы структур бүлекчәнең бурычлары һәм функцияләре һәм дәүләт хезмәтенең шушы органда биләнүче вазыйфаның функциональ үзенчәлекләре нигезендә җаваплылыгы» сүзләрен «вазыйфаи бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 30 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктта «башка дәүләт органына» сүзләрен «яллаучы вәкиле тәкъдиме белән шул ук дәүләт органында йә башка дәүләт органында дәүләт хезмәтенең башка вазыйфасына» сүзләренә алмаштырырга;

б) $9^1$ пунктта «хезмәт урынына» сүзләрен «дәүләт хезмәте узу урынына» сүзләренә алмаштырырга;

в) $9^2$ пунктта «яңа хезмәт урынында» сүзләрен «дәүләт хезмәте узуның яңа урынында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 39 статьяның 4 өлешендә «дәүләт хезмәтенең яңа урынына» сүзләрен «дәүләт хезмәте узуның яңа урынына» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 58-ТРЗ